

# Зәки Нури

# “Туган як көе”





Иң матур җире дөньяның-
Син, минем туган ягым;
Саф җилләрен дүрт елганың
Дулкынын куган ягым!

 

Татлы булып урманыңда
Җиләкләр пешә синең;
Бормалы су буйларында
Тирәкләр үсә синең.





Синең якты таң нурларын
Куанып көтә күңел;
Яуса ләйсән яңгырларың,
Сафланып китә күңел.



Үзем күрдем, үзем беләм:
Кар яуган чагың ямьле;
Зәңгәр күлләр күзе белән
Караган чагың ямьле.

 

Әйтерсең кып-кызыл болыт-
Миләшең, баланнарың.
Чигүле келәмдәй булып
Җәелә аланнарың.



Хуш исең синең сихәтле,
Шифалы синең һаваң;
Суыңны эчтем нихәтле-
Шул булды минем дәвам.



Дулкыннар үрләде үргә-
Иделне диңгез иттең;
Йолдызлар кабызып җирдә
Төннәрне көндез иттең.





Казаның үсте, яңарды,
Цехларың якты синең;
Дөньяга даны таралды-
Мехларың затлы синең.



Ишекләрен вузларыңның
Киң итеп ачты илем.
Егетләрең – кызларыңның
Эшләрен мактый илем.



Кайларга үтсә дә юлым,
Кай якка йөрсәм дә мин;
Кушкан чакта туган илем
Ут – суга керсәм дә мин,



**Сине, туган яккаемны,**
**Куанып кочар күңел,-**
**Сандугачлы, аккаенлы**
**Җирләргә очар күңел.**









